| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**О повышении размеров должностных окладов государственных гражданских служащих Республики Татарстан**

В соответствии с частью 12 статьи 23 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» **постановляю**:

1. Повысить с 1 октября 2022 года размеры месячных окладов государственных гражданских служащих Республики Татарстан в соответствии с замещаемыми ими должностями государственной гражданской службы Республики Татарстан (далее – должностные оклады государственных гражданских служащих Республики Татарстан), установленные в соответствии с Указом Президента Республики Татарстан от 22 марта 2018 года № УП-239 «О денежном содержании государственных гражданских служащих Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 3 мая 2018 года № УП-347, от 4 августа 2018 года № УП-550, от 13 августа 2019 года № УП-466 и от 1 февраля 2021 года № УП-73) и Указом Президента Республики Татарстан от 22 марта 2018 года № УП-242 «О должностных окладах лиц, замещающих должности государственной гражданской службы Республики Татарстан в Аппарате Президента Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 15 октября 2020 года № УП-697 и от 12 июля 2021 года № УП-565).

2. Для исчисления размеров должностных окладов государственных гражданских служащих Республики Татарстан в соответствии с пунктом 1 настоящего Указа индексировать в 1,04 раза размер должностного оклада специалиста 3 разряда категории «обеспечивающие специалисты» младшей группы должностей в территориальных органах органов исполнительной власти Республики Татарстан, который составит 11 958 рублей.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан осуществлять финансовое обеспечение расходов, связанных с реализацией настоящего Указа, в пределах бюджетных ассигнований, предусмотренных в бюджете Республики Татарстан на соответствующий финансовый год.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

Казань, Кремль
19 августа 2022 года
№ УП-575

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясының 12 өлеше нигезендә **карар бирәм:**

1. 2022 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указында (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы, 2018 елның 4 августындагы ПУ-550 номерлы, 2019 елның 13 августындагы ПУ-466 номерлы һәм 2021 елның 1 февралендәге ПУ-73 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-242 номерлы Указында (Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 15 октябрендәге ПУ-697 номерлы һәм 2021 елның 12 июлендәге ПУ-565 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) билгеләнгән, алар биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына нигезләнгән айлык окладлары (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфаи окладлары) күләмен арттырырга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре айлык окладлары күләмен исәпләгәндә, әлеге Указның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары территориаль органнарының кече төркем вазыйфалары «тәэмин итүче белгечләр» категориясе 3 разрядлы белгеченең вазыйфаи окладлары күләмен 1,04 тапкырга индексацияләргә һәм ул 11 958 сум тәшкил итәчәк.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованияләре чикләрендә финанслауны башкарырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 19 август
№ ПУ-575